**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» апрель, 2020 ел № 484

2020 елның II кварталына
гражданнар керменең һәм
салым салынырга тиешле мөлкәт
хакының иң чик күрсәткечләрен
раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2020 елның 16 мартындагы 67 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» Коммерцияле булмаган партнерлык хаты нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 ст. нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

2020 елның II кварталына гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 346 878,50 сум
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 714 209 сум
1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 203 983 сум
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 938 644 сум

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 3 673 305 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 4 407 966 сум

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 5 142 627 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 16 145,30 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 10 274,28 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 8 806,53 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне гражданнарны исәпкә алу һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү максатларында аз керемлеләр дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин